**Класс**: 6

**Укытучы**: Насыбуллина Резедә Сәйрин кызы

**Программа:** Җәмгыять белеме. 6 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы /(Л.Н.Боголюбов һ.б., русчадан Л.Н.Гыймадеева тәрҗемәсе)-Казан: Татар.нәшр., 2020.-160 б.:рәс.б-н.

**Тема**: Мавыгулар дөньясы

Слайд 1

Шундый көнчыгыш мәкале бар: "Иң озын сәяхәт беренче кечкенә адымнан башлана". Мөһим адымыбызны синең белән бергәләп ясыйк. Эшләргә дә, ял итәргә дә, яраткан эшебез белән шөгыльләнергә дә өлгерер өчен, вакытыбызны дөрес бүләргә өйрәник. Кызганыч, моны һәркем булдыра алмый.

Слайд 2

Вакытны дөрес бүлү өчен, иң башта кайсы эшләреңнең мәҗбүри икәнен ачыкла. Беренчедән, бу- уку. Икенчедән, бу- мәктәптә һәм өйдә үз вазифаларыңны башкару.

Слайд 3

Мәҗбүри эшләрдән соң калган вакытны буш вакыт дип атыйлар. Ул ял итү, мавыгуларың белән шөгыльләнү, үсешең һәм үз рәхәтең өчен кирәк. Бу- үзең ничек телисең, ничек кирәк дип табасың, шулай файдалана торган вакыт. Ләкин буш вакытны берни дә эшләмәү дип аңларга кирәкми. Бу – һәркем үзе сайлап ала торган күптөрле ирекле шөгыльләр өчен бирелгән вакыт.

Слайд 4

Буш вакыт һәм физкультура белән шөгыльләнү.

Кайбер фантастлар киләчәк кешесен зур башлы һәм физик яктан үсеш алмаган гәүдәле итеп сүрәтлиләр. Алар моны болай аңлата: киләчәктә барлык физик хезмәтне кеше урынына төрле машиналар, механизмнар башкарачак. Кешегә акыл хезмәте генә калачак.

Слайд 5

Әлеге фантастик образга охшамас өчен, мускулларыңа өзлексез физик авырлык биреп торырга кирәк: физик күнегүләр ясарга, физик эш һәм спорт белән шөгыльләнергә, күбрәк хәрәкәтләнергә. Акыл хезмәте белән шөгыльләнүчеләр бакчада, кырда, дача участогында эшләүне тикмәгә генә ял дип исәпләмиләр.

Саф һавада актив ял итү сиңа да файдалы.Уку дәресләре бер үк төрле позада утырырга мәҗбүр итә, ә бу мускулларның аерым бер төркемен ялыктыра. Аларның киеренкелеген йомшартырга кирәк. Моңа хәрәкәт белән генә ирешергә була. Күбрәк йөрергә, йөгерергә, йөзәргә, велосипедта йөрергә, тимераякта һәм чангыда шуарга, волейбол, бадминтон, башка хәрәкәтле уеннар уйнарга кирәк. Шуны бел: даими физик кунекмәләрнең, көндәлек физик авырлыкларның бер өлешен иртәнге физик күнегүгә, спорт секциясенә, туристик клубка, бию түгәрәгенә яисә һавада йөрергә, туп уйнарга, баудан сикерергә багышларга мәҗбүр итмәячәк.

Слайд 6

Буш вакыт: телевизор, компьютер  һәм кесә телефоны.

Слайд 7

Беркем дә телевизор, компьютер һәм заманча кесә телефонының кеше акылының бөек казанышлары булуы белән бәхәсләшә алмый. Өйдән чыкмыйча гына, дөньяда нинди вакыйгалар баруын белергә, иксез-чиксез бозлыкларны һәм чүлләрне, ыргылып агучы шарлавыкларны һәм серле мәгарәләрне, сәер хайваннарны һәм кошларны күрергә, шулай ук таныш һәм таныш булмаган кешеләр белән аралашырга була. Дөрес, экранга көнгә ике сәгатьтән артык карап утырырга ярамый, юкса ул сәламәтлегеңә зыян салачак. Тавыштан һәм төрле мәгълуматтан баш мие талчыга, күз күреме дә арый. Башка шөгыльләргә дә вакыт калмый.

Слайд 8

Ял көннәрендә киләсе атна өчен телетапшырулар программасын карап, нәрсә караячагыңны билгеләп куярга киңәш бирәбез.  Ул тапшыруларны сайлаганда, шундый сорауларга җавап бир: бу сиңа файдалы булачакмы? Аннан син канәгатьлек алачаксынмы? Ул сиңа сөенеч китерәчәкме?

Слайд 9

Компьютер артында кайсы көннәрдә һәм күпме вакыт утырачагыңны да алдан планлаштыр. Анда син нәрсә эшләргә уйлыйсың: уйныйсыңмы, электрон почтаңны тикшерәсеңме, Интернетка керәсеңме? Шуны белеп тор: компьютер уеннары уйнаганда һәм Интернетта утырганда вакыт исәбен оныту, димәк, башка мөһимрәк эшләрне эшләргә өлгермәү куркынычы бар.

Слайд 10

Үз кулларың белән

Мөгаен, сыйныфташларыңның берсе төрле файдалы әйберләр, мәсәлән, процессор астына аскуйма, ноутбук өчен тоткыч һ.б. ясарга яратадыр. Ә

кемдер агачтан төрле эшләнмәләр кисә һәм анда, яндырып, бизәкләр төшерә беләдер. Ә кызлар арасында бәйләргә яисә чигәргә яратучылар бардыр. Барлык бу шөгыльләр үзләре дә, кешенең үсешенә йогынты ясавы белән дә файдалы.

Фикерләү сәләтенең кайбер төрләре куллар нечкә, пөхтә эшләр башкарганда, төгәл исәпле хәрәкәтләр ясаганда гына үсә-бу турыда белү сиңа да кызыклыдыр. Димәк, куллар төгәл һәм ачык фикерләргә өйрәтә.

Слайд 11

Нәрсә ул хобби?

Әгәр нинди дә булса шөгыль кешенең мавыгуына әйләнсә һәм ул аңа күп вакытын багышларга теләсә, шул шөгыль хакына башка нәрсәдән ваз кичәргә дә әзер булса, моны аның хоббие дип әйтергә була.

Слайд 12

Маркалар җыю, футбол уйнау, хайваннар тәрбияләү һәм үсемлекләр үстерү, гитарада уйнау һәм китап уку хобби була ала.

Ә ул билгеле бер шөгыль, сәнгать төре, аерым бер тема белән кызыксынудан башлана. Кызыксынуың тагын да күбрәк укуыңны, белүеңне "сорый". Һәм бу өлкәдә сиңа китаплар, журналлар, музейлар күргәзмәләр, театрлар танып-белүгә багышланган телетапшырулар, Интернет ярдәм итә.

Слайд 13

Мәсәлән, Алёшаларның бөтен гаиләсе фонотека туплау белән мавыга. Бу аларга каян килгән? Бервакыт Алешанын бабасы, әле яшь чагында, радиодан бөек җырчы Ф.И.Шаляпин башкаруында халык җырын тыңлаган. Аның тавышы, музыканың характеры һәм рухы бабасын бик дулкынландырган. Өйдә Ф.И.Шаляпин җырлары язылган грампластинкалар җыю шулай башланган. Еллар узган, коллекция тулылана барган. Бу мавыгу аның балаларына, аннары оныкларына күчкән. Бүген  Алешалар гаиләсендә бик зур фонотека – бөек җырчы башкаруында күптөрле язмаларны эченә алган грампластинкалар, дисклар, кассеталар бар

**Практик өлеш**

Слайд 14

Балалар, түбәндәге сорауларга җавап бирегез.Үзегезнең җавапларыгызны дөрес җаваплар белән чагыштырыгыз.

1) Кайсы вакытны буш вакыт дип атарга мөмкиң?
2) Ни өчен "Минутның – бәясен, секундның исәбен бел", "Ял итү-эшчәнлек төрләренең алмашынуы" диләр? Аңлатып бир.

3) Нинди мавыгулар-хоббилар беләсең? Үзеңнең нинди мавыгуларың бар?

Буш вакытны ничек файдалы эшләр белән тутырырга?

Җаваплар:

1) Мәҗбүри эшләрдән соң калган вакытны буш вакыт дип атыйлар. Ул ял итү, мавыгуларың белән шөгыльләнү, үсешең һәм үз рәхәтең өчен кирәк. Бу- үзең ничек телисең, ничек кирәк дип табасың, шулай файдалана торган вакыт. Ләкин буш вакытны берни дә эшләмәү дип аңларга кирәкми. Бу – һәркем үзе сайлап ала торган күптөрле ирекле шөгыльләр өчен бирелгән вакыт.
2) "Минутның – бәясен, секундның исәбен бел" мәкале безне вакытны дөрес үткәрергә өйрәтә. Кешенең Һәрбер минуты юкка, кирәкмәгән эшкә үткәрелмәсенлеген аңлата.

"Ял итү-эшчәнлек төрләренең алмашынуы". Кеше тырышып эшләсә- ял итүе дә татлырак була. Кеше гел ял итеп кенә яши алмый, эшсез ял юк дигәнен аңлата.

3) Маркалар җыю, спорт белән шөгыльләнү, рәсем ясау, робототехника белән кызыксыну
4) Иң баштан мәҗбүр булган эшләреңне бетер. Аннары тормышыңа спорт белән шөгыльләнү керт. Буш вакытыңны мавугыларыңа, хоббиларыңа багышла. Һәрбер минутың юкка үтмәсен. Компьютерда уйнау, телефонда утыру – вакытны әрәм итү дигән сүз.

**Йомгаклау**